КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 июнь г.Казань № 507

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бер тапкыр бирелә торган түләүне түбәндәгеләргә билгеләргә:

мөрәҗәгеть итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче 25 яшькә кадәрге хатын-кызларга беренче баласы туганда 50 мең сум күләмендә;

мөрәҗәгеть итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче 29 яшькә кадәрге хатын-кызларга өченче баласы туганда 100 мең сум күләмендә.»;

2 пунктта «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгеть итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга беренче (өченче) баласы туганда бер тапкыр түләү (алга таба – бала туганда бер тапкыр түләү) бирү тәртибе турында нигезләмә»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә мөрәҗәгеть итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга беренче (өченче) баласы туганда бер тапкыр түләү (алга таба – бала туганда бер тапкыр түләү) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.»;

7 пунктның алтынчы абзацында «авыл җирлегендә,» сүзләреннән соң «шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин